**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# 2018 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премияләрен бирү турында

Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты тәкъдимнәрен караганнан соң **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премияләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) Ганибаев Рифат Шаһит улына – «Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Татарстан республика оешмасы» – «Татарстан Республикасының инвалидлар җәмгыяте» иҗтимагый оешмасы рәисенә;

2) Тимуца Ольга Вадимовнага – «Ретт синдромлы авыруларга ярдәм итү ассоциациясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасы директорына;

3) Халиков Тимур Рафаэль улына – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары, «РОССИЯНЕҢ ҮЛЕМСЕЗ ПОЛКЫ» гомумроссия иҗтимагый граждан-патриотик хәрәкәтенең Татарстан Республикасындагы төбәк штабы җитәкчесенә;

4) «Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама муниципаль районы хатын-кызлары» җирле иҗтимагый оешмасына;

5) «Ярдәм» ислам хәйриячелек милли фондына;

6) «Татарстан Республикасында чуваш милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасына;

7) «Татарстан Республикасы ирекләләр хәрәкәтен үстерү үзәге» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасына;

8) Татарстан Республикасы ветераннарының (пенсионерларының) төбәк иҗтимагый оешмасына.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 10 октябрь
№ ПУ-716